РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ГЛАВА
ГОРОДА ЧИСТОПОЛЬ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШЛЫГЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**2025 елның 1 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 31**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Чистай шәһәр Советының "2024 елгы
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
Районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге
бюджеты үтәлеше турында" карары проекты
буенча ачык тыңлаулар үткәрү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының "Ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында" 2018 елның 27 июнендәге 26/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «2024 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча 2025 елның 28 апреленә 11-00 сәгатьләрдә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты конференц-залында түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 йорт.

2. Фикер алышына торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы булган гаризалар язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрелә дип билгеләргә: Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 46 йорт, 10 каб., 5-27-27 факсы буенча яисә электрон почта адресына – chistay@tatar.ru ачык тыңлаулар уздырган көнгә кадәр. Чыгыш ясау хокукы булган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гаризалар эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12-00 сәгатьтән 13-00 сәгатькә кадәр) кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «2024 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын (алга таба оештыру комитеты) түбәндәге составта төзергә:

М.И. Ксенофонтов - Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары;

Н.А. Карманова- Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе (килешү буенча);

Н.В. Миңнегалиев - 13 нче сайлау округы буенча Чистай шәһәр Советы депутаты, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

А.В. Зайцев - 18 нче сайлау округы буенча Чистай шәһәр Советы депутаты, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясе рәисе урынбасары;

А.Р. Хаматов- Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

А.Ю. Филиппова- Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы баш белгече;

-Е.А. Солодов - «Тегермән мәйданы» 4 нче ТИҮ җитәкчесе (килешү буенча).

4. Кушырга:

- оештыру комитетына күрсәтелгән карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- Чистай шәһәре Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы утырышына проектны кертергә.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «2024 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» карарын һәм карар проектын билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Уздырыла торган гавами тыңлаулар буенча материалларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И. Ксенофонтов